| МИНИСТЕРСТВО СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК МИНИСТРЛЫГЫ |
|---|---|

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

11.03.2016 Казан ш. № 32/2-пр

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2016 елның 8 апрелендә теркәлде, № 3288

“2015-2017 елларга Татарстан Республикасында крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү” ведомство программасында катнашу өчен крестьян (фермер) хуҗалыкларын сайлап алу буенча конкурс турында” 12.03.2015 ел, №32/2-пр Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгы белән расланган Гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә грантлар бирү турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

“Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 28 февраль, 2012 ел, №165 карарын тормышка ашыру турында” 22 март, 2012 ел, №198 Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы боерыгын үтәү йөзеннән, һәм Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы белән Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югарыгы башкарма органы арасында төзелә торган “Федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъекты бюджетына субсидияләр бирү турында” 5 февраль, 2015 ел, №48/17-с Килешү нигезендә, боерык бирәм:

1. “2015-2017 елларга Татарстан Республикасында крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү” ведомство программасында катнашу өчен крестьян (фермер) хуҗалыкларын сайлап алу буенча конкурс турында” 12.03.2015 ел, №32/2-пр Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгына (алга таба – Боерык) №2 кушымтаны яңа редакциядә (кушымта итеп бирелә) бәян итәргә.

2. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Татарстан Республикасы муниципаль районнарындагы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләре начальникларына крестьян (фермер)

хуҗалыкларына 2016 елда “2015-2017 елларга Татарстан Республикасында крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү” программасында катнашулары турында хәбәр итәргә

3. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының финанслау бүлеге начальнигы М.А.Мәхмүтевкә билгеләнгән лимитлар чикләрендә акча средстволарын җиткерүне тәэмин итәргә.

4. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Р.Р.Хәбиповка йөкләргә.

Татарстан Республикасы Премьер-министры
урынбасары – министр М.Г.Әхмәтов

ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 12.03.2015 ел, №37/2-пр боерыгы (ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 11.03.2016 ел, №32/2-пр редакциясендә) белән расланды

**Гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә грантлар бирү турында нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Нигезләмә "Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 28 февраль, 2012 ел, №165 карарын тормышка ашыру турында" 22 март, 2012 ел, №198 Россия Федерациясе Авыл хуҗалыгы министрлыгы боерыгы һәм "2015-2017 елларга Татарстан Республикасында крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү" ведомство программасында катнашу өчен крестьян (фермер) хуҗалыкларын сайлап алу буенча конкурс турында" 12.03.2015 ел, №32/2-пр Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы боерыгы белән расланган "2015-2017 елларга Татарстан Республикасында крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү" ведомство программасы (алга таба – Программа, Министрлык) нигезендә эшләнде.

Бу Нигезләмә дәүләт ярдәмен бирү тәртибен, проектларны сайлап алу критерийләрен проектларны конкурс нигезендә сайлап алуны оештыру һәм үткәрү максатларын, шартларын, процедурасын билгели.

Бу Нигезләмәдә кулланыла торган төп төшенчәләр:

**мөрәҗәгать итүче** – үзен Программада катнашучы буларак таныту өчен конкурс комиссиясенә заявка тапшыручы һәм бу Нигезләмәнең таләпләренә җавап бирүче крестьян (фермер) хуҗалыгы (алга таба – КФХ) башлыгы;

**гаилә терлекчелек фермасы** – КФХ милкендәге яки аның файдалануындагы авыл хуҗалыгы терлекләрен үрчетү һәм асрау өчен билгеләнгән җитештерү объекты;

**гаилә терлекчелек фермасын үстерүгә грант** – түбәндәгеләрне кертеп, Татарстан Республикасы авыл җирлекләре территориясендә һәм авылара территорияләрдә КФХ булдыру һәм үстерү максатыннан чыгып, федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан һәм (яки) җирле бюджеттан КФХ башлыгының кредит оешмасында ачылган счетына үзенең чыгымнарын финанслашу өчен тапшырыла торган, Программа нигезендә дәүләт ярдәменең башка юнәлешләре кысаларында кире кайтарылмый торган средстволар:

гаилә терлекчелек фермаларын төзү, реконструкцияләү яки модернизацияләүнең проект документларын эшләү;

гаилә терлекчелек фермаларын төзү, реконструкцияләү яки модернизацияләү;

терлекчелек продукциясен эшкәртү буенча производство объектларын төзү, реконструкцияләү яки модернизацияләү;

гаилә терлекчелек фермаларын һәм терлекчелек продукциясен эшкәртү буенча объектларны җиһазлар һәм техника белән тәэмин итү, шулай ук аларны монтажлау;

авыл хуҗалыгы терлекләрен сатып алу (алга таба – грант).

**конкурс комиссиясе** – гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә грантлар бирү өчен КФХ проектларын сайлап алу максатыннан чыгып оештырылган ведомствоара конкурс комиссиясе;

**экспертлар советы** – Министрлык тарафыннан заявкаларны карап тикшерү һәм алга таба документларны конкурс комиссиясенә тапшыру өчен оештырылган совет;

**чыгымнар планы** – мөрәҗәгать итүче тарафыннан конкурс комиссиясе раславына тапшырылган, гранттан файдалану юнәлешләре буенча чыгымнарның статьялап күрсәтелгән сметасы;

**грант алучы** – үзен Программада катнашучы буларак таныту өчен конкурс нигезендә сайлап алу аша үткән һәм грант алуга килешү төзегән КФХ башлыгы.

1.2. Грант заявкасын конкурс комиссиясе раслаган КФХ башлыгына бирелә.

1.3. Конкурс комиссиясе эшен оештыруны Министрлык хәл итә.

1.4. Грант чыгымнар планында күрсәтелгән, сатып алына торган милке, башкарыла торган эшләре бәясенең кимендә 40 процентын үз средстволары хисабына түләү бурычын үз өстенә алган КФХ башлыкларына бирелә.

КФХ башлыгының грант хисабына сатып алынган мөлкәтен, грант алынганнан соң 10 ел эчендә, сатарга, бүләк итәргә, арендага, башка затларга файдалануга тапшырырга, алыштырырга яки пай рәвешендә кертергә, кертемгә әйләндерергә яки башкача рәвештә кая да булса урнаштырырга ярамый. Әлеге шарт гаилә терлекчелек фермаларын һәм терлекчелек продукциясен эшкәртү предприятиеләрен үстерүгә грантлар бирү буенча чараларда катнашучылар өчен мөһим шарт булып тора.

## 2. Грантлар күләме һәм аларны бирү шартлары

2.1. Грантлар, техник-икътисадый нигезләнешкә туры китереп, максатчан чыгымнарны финанслашу шартларында, кире кайтарылмый торган нигездә гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә грант алучыларга җибәрелә.

2.2. Грантлар гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә чыгымнар планында билгеләнгән чыгымнарның һәр статьясыннан күп дигәндә 60 проценты күләмендә, әмма бер мөрәҗәгать итүчегә күп дигәндә биш миллион сум күләмендә генә бирелә.

2.3. Грантлар проект егәрлеге түбәндәгечә булган шартларда бүлеп бирелә:

сыерларының баш саны 50дән ким булмаган сөтчелек фермаларына;

мөгезле эре терлекне симертү фермаларына – кимендә 100 баш;

дуңгыз фермаларына – кимендә 20 дуңгыз, шул исәптән ун ана дуңгыз;

сарык үрчетү фермаларына – кимендә 300 баш сарык-тәкә, шул исәптән, кимендә 100 баш сарык;

савым кәҗәләре – кимендә 100 баш;

кошчылык фермалары – кимендә 4 мең баш бройлер, 4 мең баш йомырка салучы тавык, 2 мең баш каз яки 2500 баш үрдәк;

кошчылык фермаларына – кимендә 20 мең баш бытбылдык;

күркә үрчетү фермаларына – кимендә 2 мең баш;

ат фермаларына – кимендә 200 ат, шул исәптән, кимендә 50 бия;

товарлыклы балык җитештерү (үрчетү) фермалары – елына кимендә 20 тонна.

2.4.Грантлар тиешле елга һәм планда каралган чорга федераль бюджет һәм Татарстан Республикасы бюджеты турында законнар нигезендә шушы максатлар өчен Министрлыкка күздә тотылган бюджет средстволары чикләрендә бирелә.

2.5. Конкурста катнашу өчен КФХ түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

а) КФХ башлыгы һәм әгъзаларының туганлык элемтәләренә ия булып, үзләренең шәхсән катнашуы нигезендә уртак җитештерү эшчәнлеге алып баручы Россия Федерациясе гражданнары (кимендә икәү) булып торуы;

б) конкурска заявка тапшыру датасына КФХ эшчәнлеге срогының теркәлү датасыннан соң 12 айдан артыграк булуы;

в) КФХның фәкать Татарстан Республикасы муниципаль районы территориясендә дәүләт теркәвенә алынуы һәм җитештерү эшчәнлеге алып баруы, Татарстан Республикасы Конституциясенең 65 статьясы нигезендә республика әһәмиятендәге шәһәрләрдән тыш;

г) хуҗалык башлыгы һәм әгъзаларының элегрәк КФХ булдыру һәм үстерүгә грантлар, гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә грантлар алучылар булып тормавы, яисә КФХ булдыру һәм үстерүгә грантның, яңа эшли башлаган фермерларның көнкүрешен җайга салуга бер тапкыр бирелә торган ярдәмнең, гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә грантның тулысынча үзләштерелү датасыннан соң кимендә өч ел узуы;

д) хуҗалыкның “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында” 24 июль, 2007 ел, №209-Ф Федераль Закон нигезендә микропредприятие критерийләренә туры килүе;

е) хуҗалыкның үзенең яки башка авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләре белән берлектәге терлек азыгы базасын булдыру өчен шартларны күздә тотуы яки терлек азыгы сатып алуга килешүләр (башлангыч килешүләр) төзү буенча тәкъдимнәр әзерләве;

ж) хуҗалыкның, авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү һәм куллану балансларыннан һәм эпизоотик хәлләргә каршы чаралардан чыгып, Программада күздә тотылган терлекчелек эшчәнлегенең бер юнәлеше (бер тармак) буенча бердән артык булмаган гаилә терлекчелек фермасын булдыруны планлаштыруы яки бердән артык булмаган гаилә терлекчелек фермасын реконструкцияләүне планлаштыруы;

хуҗалыкта терлекчелек продукциясен эшкәртү буенча үзенең базасы булмаганда һәм (яки) хуҗалык авыл хуҗалыгы куллану кооперативы әгъзасы булып тормаган очракта, хуҗалык тарафыннан планлаштырыла торган авыл хуҗалыгы терлекләренең баш саны, гаилә терлекчелек фермасын үстерү җәһәтеннән, түбәндәгедән артмаска тиеш: мөгезле эре терлек – сөтчелек яки итчелек юнәлешендәге төп ана мал – 100 баш, кәҗәләр (сарык) – 300 баш;

з) хуҗалык башлыгының хуҗалыкның урнашу теркәлү урыны буенча муниципаль берәмлектә даими яшәве яки даими яшәү өчен шунда күченү бурычын үз өстенә алуы һәм бу хуҗалыкның хуҗалык башлыгы өчен бердәнбер эш урыны булып торуы;

и) хуҗалык башлыгының Программада билгеләнгән терлекчелек эшчәнлеге юнәлеше (тармак) буенча югары җитештерүчәнлекле терлек һәм югары технологияле җиһазлар белән гаилә терлекчелек фермасын булдыру һәм үстерү, сатыла торган терлекчелек продукциясе күләмен арттыру планына, үзенә тотылган чыгымнарны каплау срогы сигез елдан артмаган, гаилә терлекчелек фермасын төзү, реконструкцияләү яки модернизацияләү нигезләнешенә (алга таба – бизнес-план) ия булуы;

к) хуҗалык башлыгының, сатып алына торган мөлкәт, башкарыла торган эшләр, күрсәтелә торган хезмәтләр (алга таба – сатып алына торган мөлкәт), аларның күләмен, бәясен, финанслау чыганакларын (грантлар, средстволары, үзенең средстволары һәм заемга алынган средстволары), атамаларын күрсәтеп, чыгымнар планын тапшыруы;

л) хуҗалык башлыгының чыгымнар планында күрсәтелгән сатып алына торган мөлкәтнең һәр атамасы бәясеннән кимендә 40 процентын, шул исәптән сатып алына торган мөлкәтнең һәр атамасы бәясеннән үз средстволары хисабына кимендә 10 процентын түләүне үз өстенә алуы:

м) хуҗалык башлыгының грантны хуҗалык башлыгы счетына акча кергәннән соң 24 ай эчендә куллану һәм грант хисабына фәкать гаилә терлекчелек фермасын үстерү һәм аның эшчәнлегенә сатып алына торган мөлкәттән файдалану бурычын үз өстенә алуы;

н) хуҗалыкның кимендә өч даими эш урынын оештыруга шартлар тудыруы;

о) КФХның гаилә терлекчелек фермасын үстерүгә грант алганнан соң кимендә биш ел дәвамында эшчәнлек алып бару бурычын үз өстенә алуы;

п) хуҗалык тарафыннан үстерү күздә тотылган терлекчелек фермасын төзүдә, реконструкцияләү, модернизацияләү һәм ремонтлауда моңа кадәр дәүләт ярдәме средстволарыннан файдаланылмавы;

р) КФХ башлыгы һәм әгъзаларының үзләренең персональ мәгълүматларын Россия Федерациясе законы нигезендә тапшыру һәм эшкәртүгә ризалык бирүе;

с) барлык дәрәҗәләрдәге бюджетларга һәм бюджеттан тыш фондларга салым түләүләре һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча түләү срогы чыккан бурычларының булмавы;

т) хуҗалык башлыгының, үзе башлык булып торган КФХдан кала, коммерция оешмасының гамәлгә куючысы (катнашучы) булып тормавы;

у) КФХга карата юкка чыгару процедурасының үткәрелмәве.

Субсидияләр алучыга карата бөлгенлеккә төшү турында арбитраж суды тарафыннан эш кузгатылганда, алар (алучылар) бу хакта эш кузгатылган көнне Министрлыкка язмача хәбәр итәргә мөмкин.

Субсидияләр үзләренә карата арбитраж суды тарафыннан бөлгенлеккә төшү турында эш кузгатылган авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә бирелми;

ф) КФХ башлыгының, килешенү буенча, грантны акча күчерү юлы белән генә тоту бурычын үз өстенә алуы.

2.6. Чыгымнар планы нигезендә, грант Грант алучы тарафыннан түбәндәгеләргә тотыла:

гаилә терлекчелек фермаларын төзү, реконструкцияләү яки модернизацияләү буенча проект документларын эшләүгә;

гаилә терлекчелек фермаларын төзү, реконструкцияләү яки модернизацияләүгә;

терлекчелек продукциясе эшкәртү буенча производство объектларын төзү, реконструкцияләү яки модернизацияләүгә;

гаилә терлекчелек фермаларын һәм терлекчелек продукциясе эшкәртү объектларын җиһазлар һәм техника белән комплектлауга, шулай ук аларны монтажлауга;

авыл хуҗалыгы терлекләрен сатып алуга.

2.7. Грант КФХ башлыгына фәкать бер тапкыр гына бирелә.

2.8. КФХ башлыгы бурычлы: грант алганнан соң биш көн эчендә, №1 кушымта нигезендә, Министрлыкка "Эшчәнлек турында мәгълүматлар" еллык һәм ярты еллык өчен хисап тапшыруга.

Чыгымнар планы нигезендә грант средстволарын һәм үзенең средстволарын тотканнан соң №2 кушымта нигезендә "Җыелма реестр", средстволарның максатчан файдаланылуын раслаган хисап-финанс документларын, ферманың фотосурәтләрен тапшыруга. Хисап документлары булып закон нигезендә хак документлар дип танылган хак документлар тора.

**3. Программада катнашу өчен конкурс комиссиясенә тапшырыла торган документлар исемлеге**

3.1. КФХ башлыгы Программада катнашу өчен түбәндәге документларны тапшыра:

3.1.1. №3 кушымта нигезендәге форма буенча заявка;

3.1.2. КФХны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе;

3.1.3. Заявка тапшыру көненә кадәр күп дигәндә өч ай алдан алынган, Хосусый эшмәкәрләрнең бердәм дәүләт реестрыннан өземтә;

3.1.4. КФХ башлыгы һәм КФХ әгъзаларының Россия Федерациясе гражданины паспортлары күчермәләре, аларның туганлык элемтәләренә ия булуын раслаучы документлар (туу турында таныклык, никахлашу турында таныклык һәм башка шундый документлар);

3.1.5. №4 кушымта нигезендә, КФХ әгъзалары арасында килешү;

3.1.6. "Авыл хуҗалыгы культуралары уңышын җыеп алу турында мәгълүматлар" №2-фермер һәм "Терлекчелек продукциясен җитештерү турында мәгълүматлар" №3-фермер формалары буенча дәүләт статистика күзәтчелеге органнарына соңгы хисап датасына хисаплар;

3.1.7. Терлекчелек продукциясен сату күләмен арттыруга юнәлдерелгән, үзенә тотылган чыгымнарны каплау срогы сигез елдан артмаган, кимендә өч даими эш урынын өстәмә рәвештә оештыру өчен шартлар тудыруны күздә тоткан гаилә терлекчелек фермасын төзү, реконструкцияләү яки модернизацияләү нигезләнеше белән, югары технологияле җиһазлар һәм югары җитештерүчәнлекле

терлек белән терлекчелек фермасын булдыру һәм үстерү буенча бизнес-план, шулай ук сатып алына торган мөлкәт, башкарыла торган эшләр, күрсәтелә торган хезмәтләр атамаларын, аларның күләмен, бәясен, финанслау чыганакларын күрсәтеп, грант хисабына финанслашуга күздә тотылган средстволар чыгымнары планы проектын – кәгазьдә һәм электрон рәвештә (№5 кушымта нигезендәге форма буенча);

3.1.8. Мөрәҗәгать итүченең чыгымнар планыннан кимендә 40 проценты күләмендә үз средстволарына һәм (яки) кредит (заем) средстволарына ия булуын раслаган документлар, шуларның 30 проценты субсидияләнми торган кредитлар булырга яки проектны тормышка ашыру өчен үзе җәлеп иткән средстволар һәм 10 проценты – үзенең акча средстволары булырга мөмкин.

Мөрәҗәгать итүченең үз средстволарына һәм (яки) кредит средстволарына ия булуын раслаучы документлар булып тора:

кредит оешмасы счетыннан өземтә яки мөрәҗәгать итүченең счетында акча средстволары булын раслаган башка документ;

кредитор (заемга бирүче) тарафыннан кредит (заем) алу мөмкинлеге турында документ, аның күләмен күрсәтеп;

мөрәҗәгать итүчегә кирәкле акча средстволарын бирү турында кредит килешүләре (заем килешүләре) күчермәләре;

проект заявка тапшыру датасына тормышка ашырылу стадиясендә булган очракта – “Россия Федерациясендә бәяләү эшчәнлеге турында” 29 июль, 1998 ел, №135-ФЗ Федераль Законда күрсәтелгән бәяләү эшчәнлеге стандартлары нигезендә бәйсез бәяләүче тарафыннан эшләнгән мөлкәтне бәяләү турында хисап. 2010 елдан соң төзелеш (реконструкция) башланып, ферманың төзелгән (реконструкцияләнгән) булуы яки кимендә 50 процент төзелеш стадиясендә булуы раслана. Үз средстволары хисабына ферманы төзү (реконструкцияләү) буенча башкарылган эшләрнең бәясе проект бәясенең кимендә 30 процентын тәшкил итә, моннан тыш кимендә 10 проценты грант алынганнан соң турыдан-туры акча средстволары белән түләнелә;

3.1.9. Мөрәҗәгать итүченең түбәндәгеләрдән торган белешмәсе:

а) “Россия Федерациясендә кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү турында” 24 июль, 2007 ел, № 209-ФЗ Федераль Закон нигезендә, КФХның микропредприятие критерийләренә туры килүен раслаган, хезмәткәрләренең уртача саны турында мәгълүматлар (моннан алдагы календарь елында хезмәткәрләренең уртача саны), гариза тапшыру вакытына мөрәҗәгать итүченең хезмәткәрләре саны, шул исәптән, КФХ башлыгы үзен дә кертеп, КФХ әгъзалары саны);

б) КФХга карата “Бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында” 26 октябрь, 2002 ел, №127-ФЗ Федераль Закон нигезендә, юкка чыгару, яки бөлгенлеккә төшү процедураларының үткәрелмәве турында мәгълүматлар;

в) хуҗалык башлыгы һәм әгъзаларының моңа кадәр крестьян-фермер хуҗалыкларын булдыру һәм үстерүгә грантлар, гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә грантлар алучылар булып тормаганлыгы турында мәгълүматлар;

3.1.10. №6 кушымта нигезендә, мөрәҗәгать итүченең җитештерү биналарына, техникага, җиһазларга, терлеккә һәм кош-кортка ия булуы турында белешмәсе;

3.1.11. Локаль сметалар һәм гаилә терлекчелек фермасының схема-сызымнары (булачак эшләр урынының фотосурәтләре, объект инде әзер булган очракта – аның эчке һәм тышкы фотосурәтләре) белән, үзкөйләнешле оешманың (алга таба – СРУ) проектлауга рөхсәте (гранттан төзү яки реконструкцияләү өчен файдаланганда) күчермәсе белән, җыелма смета исәпләмәсе;

3.1.12. Төзелешкә (реконструкция) рөхсәт (гранттан төзү яки реконструкцияләү өчен файдаланганда) яки милек хокукы турында таныклык, яисә закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә билгеләнгән, фермага аренда килешүе;

3.1.13. Заявка тапшыру датасына ким дигәндә 30 көн алдан бирелгән, барлык дәрәҗәләрдәге бюджетларга һәм бюджеттан тыш фондларга салым түләүләре һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча түләү срогы чыккан бурычның юклыгын раслаган, салым органыннан белешмә (КНД буенча форма коды 1120101);

3.1.14. №7 кушымта нигезендәге форма буенча, персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалык;

3.1.15. №8 кушымта нигезендәге форма буенча, КФХ башлыгы анкетасы;

3.1.16. Закон нигезендә билгеләнгән тәртиптә теркәлгән, җир кишәрлегенә милек хокукын һәм (яки) җир кишәрлеген арендалау килешүен дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе;

3.1.17. Мөрәҗәгать итүченең КФХның урнашу һәм теркәлү урыны буенча яшәвен раслаган, авыл (шәһәр) җирлегенең хуҗалык кенәгәсеннән өземтә;

3.1.18. КФХ башлыгының хезмәт кенәгәсе күчермәсе;

3.1.19. КФХ башлыгы – иминиятләштерелгән затның мәҗбүри пенсия иминиятләштерүе системасындагы лицевой счетыннан соңгы хисап датасына өземтә (Форма СЗИ-5);

3.1.20. Социаль иминиятләштерү фондына соңгы хисап датасына хисап күчермәсе, фондның хисапны кабул итү турында тамгасы белән (Форма – 4 ФСС);

3.1.21. Пенсия иминиятләштерүе фондына соңгы хисап датасына хисап күчермәсе, фондның хисапны кабул итү турында тамгасы белән (Форма РСВ-1 ПФР).

3.1.22. Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 22.03.2013 ел, №147 боерыгына №11 кушымтада китерелгән формада, аерым затның күчемсез милек объектларына хокуклары турында күчемсез милеккә һәм аның белән алыш-бирешләргә хокукларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (өземтәне соратып алу формасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 14.05.2010 ел, №180 боерыгы белән расланган Күчемсез милеккә һәм аның белән алыш бирешләргә хокукларның бердәм дәүләт реестрындагы мәгълүматларны тапшыру тәртибенә кушымтада китерелгән), вәкаләтле орган тарафыннан расланып, заявка тапшыру көненә кадәр күп дигәндә 30 көн алдан бирелгән.

3.1.23. КФХ башлыгының килешенү буенча грантны акча күчерү юлы белән тоту турында йөкләмәсе.

3.2. Мәгълүматларның дөреслеге һәм тапшырылган документларның чынлыгы өчен җаваплылык КФХ башлыгына йөкләнелә. Документларны әзерләү һәм конкурс комиссиясенә тапшыруга бәйле барлык чыгымнарны КФХ башлыклары күтәрә.

Раслауны таләп иткән һәм берничә биттән торган документлар тапшырганда, һәр бит раслана. Проектны яклаганда, документларның төп нөсхәләре, конкурс комиссиясендәге күчермәләр белән чагыштыру өчен, күрсәтелә.

Бу Нигезләмәнең 3.1. бүлегендә күрсәтелгән документларга КФХ башлыгы кул куярга, аларның битләре тегелгән, номер сугылган булырга һәм КФХ башлыгы мөһере (мөһере булганда) белән расланган булырга тиеш. Чистарту-бетерүләр һәм төзәтүләр рөхсәт ителми, вәкаләтле затның (юридик затлар өчен) мөһере (мөһере булганда) һәм имзасы белән расланган яки үз кулы белән раслаган (КФХ башлыгы өчен) төзәтүләрдән тыш.

3.1. бүлектә күрсәтелгән документлар конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү турында извещениедә күрсәтелгән срокларда һәм адрес буенча тапшырыла.

Грантны тапшыру тәртибе һәм документлар формалары турында мәгълүматлар Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының рәсми сайтына (http: // agro.tatarstan.ru) “Фермерларга, авыл хуҗалыгы кооперативларына грантлар һәм ЛПХга субсидияләр” бүлегенә “Россия Федерациясе бюджеты катнашында гаилә фермаларына ярдәм итү” бүлекчәсенә (алга таба – Министрлыкның рәсми сайты) урнаштырыла.

Мөрәҗәгать итүче, үзенең теләгенә карап, конкурс комиссиясенә (әңгәмә үткәрелгән вакытта) КФХны программада потенциаль катнашучы буларак уңай яктан бәяләгән, конкурс комиссиясе карарына йогынты ясый алырдай документлар тапшыра:

а) муниципаль хакимият органнарыннан КФХның үсешен, җитештерү күрсәткечләре динамикасын, шулай ук социаль-икътисадый нәтиҗәсен һәм грантны бирүнең максатка ярашлы булу-булмавын бәяләгән рекомендация хатлары;

б) авыл хуҗалыгы максатындагы объектларга милек хокукын дәүләт теркәвенә алу турында таныклыклар күчермәләре, техник средстволарның (милектә техник средстволар булган очракта) паспортлары күчермәләре.

в) җитештерү биналарының (шул исәптән тәмамланмаган төзелеш) фотосурәтләре, авыл хуҗалыгы терлекләре, техника һәм җиһазлар фотосурәтләре.

г) 2.5 һәм 3.1 пунктларында билгеләнгән таләпләр нигезендә, заявка тапшырганнан соң эшләп җиткерелгән документлар;

д) массакүләм мәгълүмат чараларында язмалар һәм, үзенең теләгенә карап, башка документлар.

**4.Заявкаларны кабул итү һәм теркәү**

4.1. Грантлар бирү буенча конкурс нигезендә сайлап алуда катнашуга заявкалар кабул итүнең башлануы турында извещение Министрлыкның рәсми сайтына урнаштырыла.

Извещениедә конкурс үткәрү урыны һәм вакыты, элемтәгә керү өчен телефоннар, Министрлык сайтының конкурс шартлары, заявкаларны тапшыру

тәртибе һәм норматив-хокукый документлар белән танышу тәртибе турында мәгълүматлар урнаштырылган бүлеге.

4.2. Заявкаларны кабул итүнең башлану срогы булып извещение басылып чыккан көннән соң килүче көн тора. Извещениедә күрсәтелгән срок чыкканнан соң КФХ башлыкларыннан заявкалар кабул ителми.

Алынган заявкалар һәм документларны теркәү, аларның алынуына карап, заявкаларны теркәүгә алу журналында хәл ителә, Журналның битләренә номер сугыла, тегелә һәм конкурс комиссиясе секретаре имзасы һәм Министрлык мөһере белән беркетелә-раслана. Заявка теркәүгә алынганда, керү номеры сугыла.

3.1. бүлектә күрсәтелгән документлар конкурс комиссиясе секретаренә кәгазьдә тапшырыла, өстәмә итеп, электрон рәвештә 3.1.7 (бизнес-план), 3.1.11 (локаль-смета исәпләмәсе һәм КФХның җитештерү бинаалары, техникасы, терлеге һәм кош-кортларының фотодокументлары) һәм 3.1.15 (анкета) пунктчаларында күрсәтелгән документлар тапшырыла. КФХ башлыгы тарафыннан конкурс комиссиясенә тапшырыла торган барлык документларның атамалары, алардагы битләр саны документлар исемлегенә кертелә, исемлек ике нөсхәдә төзелә. Тапшырылган документлар конкурс комиссиясе секретаре тарафыннан документлар исемлеге (№9 кушымта) белән чагыштырылганнан соң, конвертка салып куела, конверт ябыштырылып, КФХ мөһере белән (мөһере булганда) раслана. Шулай ук конвертта программа атамасы, ферма эшчәнлеге юнәлеше һәм аның проекттагы егәрлеге, КФХ атамасы, мөрәҗәгать итүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм адресы күрсәтелә. Документлар исемлеге конвертка салынмый. Документларны кабул иткәндә, документлар исемлеге кәгазендә, кабул итү датасын һәм теркәү номерын күрсәтеп, документларны кабул итүне раслаучы тамга куела. Документлар исемлеге кәгазенең бер нөсхәсе, кабул итү турында тамга белән, КФХ башлыгында кала, ә икенчесе документлар янына куела. Заявкаларны һәм документларны кабул иткәндә, аларның тулы булу-булмавы һәм билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәве тикшерелми.

## 5.Конкурс комиссиясе функцияләре һәм бурычлары

5.1.Конкурс комиссиясе үзенең эшчәнлегендә законнарга, бу Нигезләмәгә таяна һәм үзенең эшен авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә дәүләт ярдәме инфраструктурасын тәшкил итүче оешмалар, иҗтимагый оешмалар, крестьян (фермер) хуҗалыклары һәм аграр профильдәге мәгариф оешмалары белән берлектә оештыра.

5.2. Конкурс комиссиясенең төп бурычлары булып тора:

Гаилә терлекчелек фермаларын үстерүгә грант алу өчен мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган конкурс документларын үз вакытында, ачыктан-ачык һәм объектив төстә карап тикшерүне тәэмин итү;

тулылыгы һәм дөреслеген, икътисадый нәтиҗәсен, Татарстан Республикасы икътисады өчен социаль әһәмиятен һәм дәүләт ярдәме күрсәтүнең максатка ярашлылыгын билгеләү максатыннан чыгып, проектларга экспертиза ясау;

конкурста җиңүчеләрне һәм аларга бирелә торган грантлар күләмен билгеләү.

5.3. Конкурс комиссиясе Министрлык боерыгы белән кимендә унике кешедән төзелә һәм конкурс комиссиясе рәисеннән, рәис урынбасары, секретаре (тавыш бирү хокукыннан башка гына) һәм әгъзаларыннан тора. Конкурс комиссиясе әгъзалары исәбендә дәүләт хезмәткәрләре саны күп дигәндә 50 процент тәшкил итәргә тиеш.

Конкурс комиссиясе рәисе:

конкурс комиссиясе эшчәнлегенә җитәкчелек итә һәм үзенә йөкләнгән бурычларны үтәүгә җавап бирә;

конкурс комиссияләре әгъзалары арасында бурычларны билгели;

конкурс комиссиясе утырышларын алып баруны, утырышлар беркетмәләрен әзерләүне һәм конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителә торган карарларны тормышка ашыруны контрольлектә тотуны хәл итә.

5.4. Конкурс комиссиясе урынбасары, конкурс комиссиясе утырышында рәис булмаган очракта, аның бурычларын үти.

5.5. Конкурс комиссиясе секретаре:

заявкаларны кабул итү төгәлләнгәннән соң биш эш көне эчендә конкурс комиссиясе утырышында карап тикшерелергә тиешле тапшырылган документлар белән заявкалар исемлеген булдыра;

заявкаларны кабул итү тәмамланганнан соң биш эш көне эчендә документларны экспертлар советына карап тикшерүгә тапшыра;

конкурс комиссиясе утырышының көн тәртибе буенча материаллар әзерләүне оештыра, документлар әйләнешен һәм утырышта конкурс комиссиясе әгъзаларының катнашуын, конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсен рәсмиләштерүне тәэмин итә;

заявкаларны кабул итү төгәлләнгәннән соң 15 эш көне эчендә, мөрәҗәгать итүчеләрне әңгәмәгә чакырып, конкурс комиссиясе утырышын оештыра;

конкурс тәмамланганнан соң 30 эш көне эчендә барлык заявкаларны һәм документларны, шулай ук конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителгән барлык документларны, биш ел дәвамында саклау өчен, Министрлык архивына тапшыра.

5.6. Конкурс комиссиясе үзенә йөкләнгән вәкаләтләрне тормышка ашыру, консультацияләр алу, тапшырылган документларны өйрәнү, аларга экспертиза үткәрү һәм балларны исәпләү өчен экспертлар советын җәлеп итә.

Экспертлар советы Министрлык боерыгы белән кимендә 12 кешедән булдырыла һәм экспертлар советы рәисеннән, секретаре һәм әгъзаларыннан тора.

Экспертлар советы: конвертларны ача һәм документларның булу-булмавын тикшерә;

КФХ башлыгының һәм аның тарафыннан тапшырылган документларның таләпләргә туры килүен тикшерә;

бәяләү ведомостенә кертеп, баллар санын исәпли һәм конкурс комиссиясе каравына тәкъдим итү характерындагы бәяләмә чыгара.

Экспертлар советы рәисе:

Экспертлар совет эшчәнлегенә җитәкчелек итә һәм үзенә йөкләнгән вәкаләтләрне билгеләнгән срокта үтәүгә җавап бирә;

Экспертлар совет әгъзалары арасында бурычларны бүлә.

Экспертлар совет рәисе урынбасары, экспертлар советы рәисе югында, аның бурычларын үти.

Экспертлар советы секретаре экспертлар советы утырышын оештыра һәм конкурс комиссиясе өчен экспертлар советы бәяләмәсен әзерләүне оештыра.

Экспертлар советы утырышы КФХ башлыклары заявкаларын конкурска кабул итү төгәлләнгәннән соң 15 эш көненнән дә соңга калмыйча үткәрелә.

5.7. Конкурс комиссиясе заявкаларны кабул итү төгәлләнгәннән соң 15 эш көненнән дә соңга калмыйча конкурс комиссиясе утырышын үткәрә. Мөрәҗәгать итүчеләр тарафыннан тапшырылган документларны, туры килү турында экспертлар советы рекомендацияләрен карап тикшерә, грант суммасын билгели һәм КФХ башлыкларына грантлар бирү яки грантлар бирүдән баш тарту турында карар кабул итә, карар конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсе (алга таба – беркетмә) нигезендә рәсмиләштерелә.

Конкурс комиссиясенең һәр әгъзасы әңгәмә барышында заявкалардагы мәгълүматлар нигезендә һәм мөрәҗәгать итүченең үзенә бирелгән сорауларга җаваплары нигезендә карар кабул итә һәм, бирелә торган грантның күләмен күрсәтеп, һәр КФХ башлыгына карата тавыш бирү кәгазенә тиешенчә язып куя.

5.8. Конкурс комиссиясе карары, конкурс комиссиясе составының яртысыннан артыграгы булганда, күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар бертигез булганда конкурс комиссиясе утырышында рәислек итүченең тавышы хәлиткеч булып тора.

Бертигез күләмдә баллар җыйган берничә дәгъвачы булганда, катнашучыларның саны буенча грантлар кирәкле күләмдә булмаганда, грант заявкасы “№3 конкурска заявкаларны теркәү журналы”нда алданрак теркәлгән дәгъвачыга бирелә.

Секретарь тавыш бирү кәгазьләрендә конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан чагылдырылган карарлар нигезендә, конкурс бюллетенен төзи. Тавыш бирү кәгазьләре һәм конкурс бюллетене беркетмә янына куела.

Конкурс комиссиясе утырышлары кирәк булуга карап үткәрелә. Конкурс комиссиясе әгъзалары рәис карары буенча утырышка чакырыла. Конкурс комиссиясе секретаре утырышка өч эш көне кала электрон рәвештә тапшырылып, карап тикшерүгә планлаштырылган мөрәҗәгать итүчеләрнең документларын һәм экспертлар советы бәяләмәсен конкурс комиссиясе әгъзаларына өйрәнүгә җибәрә.

Конкурс нәтиҗәләре турында мәгълүматлар, конкурс комиссиясе тарафыннан карар кабул ителгән көннән соң 10 эш көненнән дә соңга калмыйча, Министрлыкның рәсми сайтына урнаштырыла.

5.9. Конкурс комиссиясе, түбәндәге критерийләргә таянып, экспертлар советы бәяләмәсе һәм мөрәҗәгать итүчеләр тапшырган документларга анализ нигезендә, конкурс нигезендә сайлап алу аша узган җиңүчеләрне билгели:

| № п/п | **Критерий атамасы** | **Күрсәткечләр** | **Балларда бәя** |
|---|---|---|---|
| 1 | Конкурс нигезендә сайлап алудан | 5 – 10 | 1 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | катнашу өчен заявка тапшыру вакытына терлек һәм кош-кортның баш саны (шартлы баш саны)* | 11 – 30 | 3 |
| | | 31 дән артыграк | 5 |
| 2 | Башкарыла торган эшчәнлекне ңтөрен күрсәтеп, өстәмә эш урыннарын булдыру | 4-5 урын | 1 |
| | | 6-9 урын | 3 |
| | | 10 һәм аннан күбрәк | 5 |
| 3 | Инженерлык челтәрләренә электр, су, юл, җылылык, канализация челтәрләренә тоташкан булу-булмау | Ике һәм күбрәк | 3 |
| | | бер челтәр | 1 |
| 4 | Конкурста ктанашу өчен заявка тапшыру вакытына мөрәҗәгать итүченең милкендә авыл хуҗалыгы үзйөрешле техникасының, югары җитештерүчәнлекле терлекчелек җиһазының булуы (берәмлекләрдә) | 1 – 3 | 1 |
| | | 3 – 5 | 2 |
| | | 5 тән артыграк | 3 |
| 5 | Проектны тормышка ашыру өчен җир кишәрлелкәренең булуы ** | милектә | 3 |
| | | арендада | 1 |
| 6 | Авыл хуҗалыгындагы максатындагы җир кишәрлегенең мәйданы (гектар) | 5 – 10 | 1 |
| | | 10,1 – 50 | 3 |
| | | 50 дән артыграк | 5 |
| 7 | Ферманың юнәлеше | сөтчелек һәм мөгезле эре терлекне симертү | 5 |
| | | ат үрчетү<br>кош-корт үрчетү<br>балык үрчетү | 3 |
| | | кәҗә үрчетү<br>сарык үрчетү<br>дуңгыз үрчетү | 1 |
| 8 | Мөрәҗәгать итүченең эшчәнлегенә карата турыдан-туры мөнәсәбәтле оешмалардан рекомендация хатларының (грант алу очрагында хуҗалык алып баруның уңай тәҗрибәсе турында мәгълүматтан һәм ферманы үстерү перспективасын бәяләүдән торган) булуы | ике һәм аннан күбрәк | 2 |
| | | бер | 1 |
| 9 | Мөрәҗәгать итүченең чыгымнар планыннан 40 % ы күләмендә үзенең средстволарына, кредит (заем) средстволарына ия булуы | үзенең акча средстволары – 100 % | 3 |
| | | үзенең акча средстволары – 50 % | 1 |
| 10 | **Бизнес-план бәяләмәсе** | | |
| а) | проектның үзенә тотылган чыгымнарны каплау чоры | 5 елга кадәр | 3 |
| | | 7 елга кадәр | 1 |
| б) | Авыл хуҗалыгы куллану кооперативында катнашу яки үзендә эшкәртүне һәм әзер продукция сатуны оештыру. Соңгы елларда мөрәҗәгать | үзендә эшкәртү һәм әзер продукцияне сату | 7 |
| | | авыл хуҗалыгы кооперативы аша сату | 3 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | итүче тарафыннан эшкәртү һәм сату өчен тапшырылган продукция күләмнәре турында мәгълүмат күрсәтелә. | чит эшкәртүчегә сату | 1 |
| в) | Үзенең терлек азыгы продукциясенә ия булуы | 50 процентка кадәр үзеенң терлек азыгы базасы хисабына терлек азыгы белән тәэмин ителеш | 1 |
| | | 100 процентка кадәр | 3 |
| г) | Проект егәрлегенә чыкканнан соң производствоны ңрентабельлелеге | 10-20 процент | 1 |
| | | 21 процент һәм аннан күбрәк | 3 |
| 11 | Проектның уңышлы тормышка ашыруның төп факторлары буенча белемне бәяләү (әңгәмәдән соң хәл ителә) | | Максималь балл – 20 |

Искәрмәләр:

* 1 пунктта күрсәтелгән күрсәткечне исәпләгәндә, терлек һәм кош-кортны шартлы башка күчерүнең түбәндәге коэффициентлары кулланыла: мөгезле эре терлек (зур) һәм атлар – 1,0; мөгезле эре терлек (яшь терлек) – 0,6; дуңгызлар – 0,3; сарыклар һәм кәҗәләр – 0-1; кош-корт – 0,02; балык өерендә ана балыклар, мәрсин балыклардан тыш – 0,2; мәрсин балык өерендә ана балыклар – 0,4.

** Мөрәҗәгать итүченең милектә, шулай ук арендага алынган җир кишәрлекләре булган очракта, “Проектны тормышка ашыру өчен җир кишәрлекләренең булуы” № 5 пунктта баллар саны җир кишәрлекләренең гомуми мәйданыннан милектәге һәм арендадагы җирләр өлешеннән чыгып исәпләнелә.

5. 10. Бәяләнелә торган проектларның һәркайсы буенча 5.9 пунктта күрсәтелгән критерийләр буенча мөрәҗәгать итүченең баллар суммасы буларак билгеләнелә торган йомгаклау баллы чыгарыла. Баллар фәкать тегелгән документлар буенча гына исәпләнелә. Конкурс комиссиясе утырышында тәкъдим ителгән документлар баллар суммасына өстәмә баллар китерми. Балларның максималь дәрәҗәдә мөмкин булган саны – 70. Конкурс комиссиясенең уңай карарын чыгару өчен 30 балл тупларга кирәк.

5.11. Беркетмәгә утырышта катнашкан конкурс комиссиясе рәисе яки аның урынбасары, секретаре һәм әгъзалары кул куя. Протокол имзаланганнан соң Министрлык биш көн эчендә конкурс нигезендә сайлап алу нәтиҗәләрен раслау турында боерык чыгара һәм Татарстан Республикасы муниципаль районнарында Министрлыкның Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәләренә, конкурста катнашучыларга җиткерү өчен, конкурс комиссиясе тарафыннан кабул ителгән карар турында язмача уведомление җибәрә.

5.12. Конкурс заявкасын карап тикшерү нәтиҗәләре буенча (шул исәптән техник хата очрагында) грант бирүдән баш тартылган мөрәҗәгать итүченең шикаятен карап тикшерү, тавыш бирү юлы белән, кабул итеп алынган

мәгълүматның бу Нигезләмәгә туры килү-килмәвен карап тикшерү өчен, конкурс комиссиясенең өстәмә утырышы үткәрелә. Мөрәҗәгать итүчеләрнең шикаятьләрен карап тикшерү буенча конкурс комиссиясенең өстәмә утырышы алдагы утырыш үткәрелгәннән соң 5 эш көне эчендә үткәрелә. Тавыш бирү нәтиҗәләре беркетмә нигезендә рәсмиләштерелә. Бу хакта мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә.

5.13.Конкурс тапшырылган заявкалар саны яки грант откан фермерлар саны үзләренә финанс средстволары бүлеп бирелгән фермерлар санынннан кимрәк булган очракта, Министрлык яңа конкурс игълан итә.

5.14.Грант алучы, үз теләгенә карап, түбәндәге очракта гариза тапшыра:

а) түбәндәгеләр үзгәргәндә: чыгымнар планы, чыгымнар планындагы суммалар, сатып алына торган милек атамалары, ферма эшчәнлеге юнәлешләре, акчалата средстволардан файдалану формасы, гранттан максатчан файдалану турында хисап тапшыру срогы;

б) бу Нигезләмә кысаларында бурычларны үтәүгә комачаулардай хәлләр турында.

Гаризаларны карап тикшерү конкурс комиссиясенең чираттагы утырышында, әгъзаларының тавыш бирүе нигезендә, хәл ителә, карап тикшерү нәтиҗәләре тавыш бирү кәгазендә һәм конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсендә теркәлә.

## 6. Грант тапшыру һәм аны кире кайтару тәртибе

6.1. Грант КФХ башлыгына Министрлык боерыгына туры китереп, грант бирү турында килешү һәм беркетмә нигезендә бирелә.

Заявкалары грант бирүгә уңай бәяләмә алган КФХ башлыклары конкурс нигезендә сайлап алу нәтиҗәләре турында мәгълүматлар алынганнан соң биш эш көне эчендә Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыра:

а) № 10 кушымта нигезендәге форма буенча, белешмә-исәпләмә;

б) № 11 кушымта нигезендә, конкурс комиссиясе тарафыннан расланган юнәлешләр буенча чыгымнар планы;

в) № 12 кушымта нигезендәге форма буенча, грант бирү турында килешү.

6.2. Министрлык  грант алу өчен тапшырылган документларны, аларның керүенә карап, журналга терки, журнал битләренә номер сугыла, тегелә һәм Министрлык мөһере белән беркетелә – раслана. Теркәүгә алу язуы теркәү номерын, документларны кабул итү датасын һәм конкурс нәтиҗәләре буенча грант суммасын үз эченә ала.

6.3.Министрлык документлар теркәлгәннән соң биш эш көне эчендә кабул итеп алынган документларны тикшерә һәм 6.1 пункты нигезендә, грант алучы тарафыннан тапшырылган чыгымнар планына, белешмә-исәпләмәгә һәм килешүгә кул куя.

6.4.Түбәндәге очракларда мөрәҗәгать итүчегә грант бирүдән баш тартыла:

6.1 пунктта күрсәтелгән документлар тулысынча тапшырылмаганда;

6.1 пункт нигезендә тапшырылган документлардагы мәгълүматларның, исәпләмәләрнең факттагы мәгълүматларга һәм исәпләмәләргә туры килмәве ачыкланганда.

6.5. Министрлык КФХ башлыкларының кредит учреждениеләрендә ачылган расчет счетларына грант күчерү өчен Татарстан Республикасы Финанс министрлыгыннан Казанчылык департаментына тапшыра.

а) Министрлыкның конкурс комиссиясе утырышы беркетмәсен раслау турында боерыгын;

б) 6.1 пунктта күрсәтелгән һәм 6.3 пункт нигезендә имзаланган килешү күчермәсен һәм грант күләме исәпләмәсен.

6.6. Министрлык бюджет средстволарын баш бүлүче булып тора һәм, Федераль казанчылык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә ачылган лицевой счетыннан, финанслау лимитлары булганда, КФХ башлыкларының Федераль казанчылык хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе территориаль бүлекләрендә ачылган лицевой счетларына, 5 эш көне эчендә, акча средстволарын күчерүне хәл итә.

6.7. Грантлардан максатчан файдалануга контрольлек итүне Министрлык хәл кыла.

6.8. Грант алучылар “Грант күләме һәм аны бирү шартлары” 2 бүлектә күрсәтелгән грант бирү шартларын бозу очрагында, закон нигезендә җавап бирә.

6.9. Грант бирү федераль бюджеттан һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан финанслау лимитларыннан чыгып хәл ителә. Грант алуга конкурс нигезендә сайлап алу аша үткән заявкаларны канәгатьләндерү өчен, аларны финанслау, бу Нигезләмәгә туры китереп, максималь баллар саны буенча чират тәртибендә хәл ителә.

Проектны тормышка ашыруны инкарь иткәндә, гранттан максатчан файдаланмау һәм грант алу өчен ялган мәгълүматлар һәм документлар тапшыру ачыкланганда, чыгымнар планы нигезендә грант средстволарын тотуга комачаулардай эшмәкәрлек эшчәнлегенең шартлары үзгәрү сәбәпле бирелгән грант суммасы закон нигезендә кире кайтарылырга тиеш.

ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы
12.03.2015 № 37/2-пр боерыгы (ТР Авыл хуҗалы
азык-төлек министрлыгының
11.03.2016 ел, №32/2–пр редакциясендә)
белән расланган нигезләмәгә
№ 1кушымта

Ешлыгы: (киләсе яртыеллыкның 10 нчы числосына кадәр)

"Килештерелде":
Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек
идарәсе начальнигы
____________________ /___________/

# Эшчәнлек турында мәгълүматлар

КФХ _______________________ _ __________________ ТР муниципаль районының ___________201_ елга

(Ф.И.О.)

“2015-2017 елларга Татарстан Республикасында крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үс
програмасы буенча _____________________________ юнәлеше буенча ______ баш.

**1. Җитештерү күрсәткечләре:**

| № п/п | Баш саны | Җитештерелгән авыл хуҗалыгы продукциясе атамасы | Авыл хуҗалыгы продукциясен җитештерү күләме, тн. | Сату күләме, тн | Керем мең сум | Чыгымнар барлыгы, мең сум | Рентабельлелек % |
|---|---|---|---|---|---|---|---|

| | Авыл хуҗалыгы терлекләре атамасы | Баш саны | | Хисап елында барлыгы | Шул исәптән хисап датасына (ярты ел өчен) | Хисап елында барлыгы | Шул исәптән хисап датасына (ярты ел өчен) | Хисап елында барлыгы | Шул исәптән хисап датасына (ярты ел өчен) | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | Сөт | | | | | | | | * |
| 2 | | | Ит | | | | | | | | * |
| 3 | | | һ.б. | | | | | | | | * |
| 4 | | | | | | | | | | | * |
| 5 | | | | | | | | | | | * |
| Барлыгы: | | | Җәмгысе: | * | * | * | * | | | | |

**2. Салым түләү, хезмәткәрләрнең саны һәм аларның хезмәт хакы:**

| № пп | Хуҗалык хезмәткәрләренең белгечлеге атамасы | Ф.И.О. | Исәпләнгән хезмәт хакы, мең сум | | Салымнар мең сум | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | Салымнар, барлыгы | шул исәптән | | | | |
| | | | Хисап елында барлыгы | Шул исәптән хисап датасына (ярты ел өчен) | | Хезмәт хакыннан чигерүләр | Җир салымы | Милеккә салым | Транспорт салымы | Бердәм авыл хуҗалыгы салымы |

| | | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | КФХ башлыгы | | | * | * | | | | | | | |
| 2 | КФХ әгъзасы | | | | | | | | | | | |
| 3 | Грант алганчы хезмәткәрләр саны ____ кеше | | | | | | | | | | | |
| 4 | Яңа кабул ителгән | | | | | | | | | | | |
| 5 | | | | | | | | | | | | |
| 6 | | | | | | | | | | | | |
| Барлыгы: | | | | | | | | | | | | |

**3. Ферманы үстерүгә грант средстволарын тотуны бәяләү.**

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1 | Җир кишәрлеге мәйданы (га) : | милектә - | арендада - |
| 2 | КФХ башлыгының субъектив фикере буенча грант нәрсәләрне эшләү мөмкинлеге биргән? | | |
| 3 | Авыл хуҗалыгы продукциясен сату һәм җитештерү ничек җайга салынган? | | |
| 4 | КФХ нинди социаль җаваплылык тота? | | |
| 5 | КФХ нинди кыенлыклар кичерә, хәл ителмәгән нинди мәсьәләләре бар | | |

| | |
|---|---|
| | |
| 6 | КФХ үстерү перспективалары - |

Мәгълүматларның дөреселеген раслыйм: КФХ башлыгы _____________ ______________ /Ф.И.О. имза/ Мөһе

ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 12.03.2015 № 37/2-пр боерыгы (ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 11.03.2016 ел, №32/2–пр редакциясендә) от белән расланган нигезләмәгә № 2 кушымта_________ )

"Килештерелде":

Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек

идарәсе начальнигы

_______________ /_________________/

# Товар-матди кыйммәтләр, хезмәт күрсәтүләр, терлек, техника сатып алуга грант

**акчасын тотуны учетка алуның җыелма реестры**

КФХ башлыгы ________________________________________________

(Ф.И.О.)

___________________авыл җирлеге ____________ ТР муниципаль районы ______________ датасына

Ферма юнәлеше

Грант суммасы _____ мең сум __________________________________

| №№<br>пп | Түләүне раслаган документ атамасы (түләү поручениесе) | Документ датасы | Документ номеры | Кайдан икәнлеге<br>(сатучы исеме) | Сатып алынган товар-матди кыйммәтләр (терлек, төзелеш материаллары, техника, хезмәт күрсәтүләр һ.б.) атамасы | Үлч. бер.<br>данә./баш $м^3$, кг | Күлә-ме | Бер берәмлек бәясе, сум | Сумма, сум | Источник финансирования (грант, привлеч.средства или собственные) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 |

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1. | | | | | | | | | | |
| 2. | | | | | | | | | | |
| 3. | | | | | | | | | | |
| 4. | | | | | | | | | | |
| 5. | | | | | | | | | | |
| 6. | | | | | | | | | | |
| | Барлыгы: | X | X | X | X | X | | X | | |

МУ Мәгълүматларның дөреслеген раслыйм: КФХ башлыгы ______________________ /Ф.И.О./ _____________________/ Имза/

ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының
12.03.2015 № 37/2-пр боерыгы (ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының
11.03.2016 ел, №32/2–пр редакциясендә) белән расланган нигезләмәгә № 3 кушымта

Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры
М.Г.Әхмәтовка

___________________________

___________________________

_______________________ дән
(КФХ башлыгы Ф.И.О., яшәү адресы)

“2015-2017 елларга Татарстан Республикасында крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү” ведомство программасында катнашучыларны конкурс нигезендә сайлап алуда катнашуга заявка

Мин, ________________________________________________________________

____________________________________________________________________ ,
(мөрәҗәгать итүченең тулы рәсми атамасы)

“2015-2017 елларга Татарстан Республикасында крестьян (фермер) хуҗалыклары базасында гаилә терлекчелек фермаларын үстерү” ведомство программасында (алга таба – Программа) катнашучылар составына кертүегезне сорыйм.

Түбәндәгеләрне раслыйм:

1. КФХ башлыгы сыйфатында эш урыным бердәнбер эш урыным булып тора.

2. Программада катнашу шартлары белән таныштым һәм алар белән килешәм.

Хуҗалыгымны Программада катнашучы буларак тану очрагында, түбәндәгеләрне үз өстемә алам:

а) чыгымнар планында күрсәтелгән чыгымнарның һәр статьясы бәясенең кимендә 40 процентын түләүне;

б) грантны үзләштергәннән соң кимендә биш ел дәвамында крестьян (фермер) хуҗалыгы эшчәнлеген алып баруны;

в) билгеләнгән срокларда хисап тапшыруны;

